ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ
«ВТ» хәбәрчесенең ил-көн вакыйгаларына карашы
> 2

СОЛДАТ АНАСЫ
«Улымны балалар уратып алгач, дөньядагы бәхетле кешегә әйләндем»
> 3

ҖУЕЛМАС ЭЗ
Танылган журналист Люция Фаршатова остазларын искә ала
> 3

МИЛЛИ АККОРД
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турындагы махсус проекты
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 19 (28986) | Чәршәмбе | 8 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИШЕГАЛДЫНА КЕМ ХУҖА?

Быел Татарстанда 960 ишегалды яңартылачак. Моның өчен 9 миллиард сум акча тотарга ниятлиләр. Ә менә республиканың 11 районында эш беткән. Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта «Безнең ишегалды» программасының үтәлеше турында сөйләделәр.

dvor.tatar

Билгеле булганча, әлеге программа Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Ул 2014 елга кадәр төзелгән күпфатирлы йортларның ишегалларын колачлый. Яңарту таләп ителгән очракта, әлбәттә. «Безнең ишегалды» программасы кысасында җәяүлеләр һәм машина юллары төзекләндерелә, балалар һәм спорт мәйданчыклары корыла, эскәмияләр, яктырткычлар һәм чүп савытлары урнаштырыла, көнкүреш калдыкларын ташлау өчен аерым урыннар булдырыла. Зур эшкә тотынганчы, республикадагы кул җитмәгән ишегалларын барлап та чыкканнар. Таганнары ватылган, юллары тузган шундый 7 меңгә якын күпфатирлы йорт территориясен чиратка куйган булганнар.

– Программа тормышка ашырыла башлаганнан бирле 3 мең 400гә якын ишегалды яңартылды инде. Биредә 25 миллиард сумлык эш башкарылды. Быел 960 ишегалдын төзекләндерәчәкләр. Моның өчен 9 миллиард сумга якын акча бүлеп биреләчәк. Шуның 7,5 миллиард сумы юл эшләренә тотылачак. 2019 елдан бирле төзекләндерү таләп ителүче ишегаллары өстәлә баруны да исәпкә алып, тагын 2–3 елга җитәрлек эш бар әле, – диде Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин.

Аның сүзләренә караганда, республиканың 11 районында программа төгәлләнгән дә инде. Биредә ишегалларын ямьләндереп бетергәннәр. Ә Татарстанның 34 районында эш дәвам итә.

– Быел кайсы ишегалдында балалар өчен комлык, әби-бабайларга эскәмия куелачагы билгеле инде, эшчеләр килəсен күпкатлы йорт хуҗалары үзләре дә белә, – ди «Безнең ишегалды» программасы кураторы Арина Петрова. – Төзелеш эшләре башланачак ишегалларында яшәүчеләр белән тәүге очрашуларны үткәреп бетердек, кәгазьләр расланды, кирәкле җиһазларга заказ бирдек. Дөньякүләм вазгыяткә бәйле рәвештә эштә тоткарлыклар булмасмы дип тә борчыласы юк. Мәсәлән, быел программа кысасында балалар, спорт һәм урам җиһазлары җитештерәчәк 18 оешманың 14е – республиканыкы. Без берьюлы ике куянның койрыгын тотабыз: программага бүлеп бирелгән акча Татарстанда калачак. Эшкә кар эреп беткәч, апрель урталарында тотынырга ниятлибез.

Татарстанның Тукай районында программага кертелгән 89 ишегалдының 50сендә эш беткән инде. Быел тагын 21 ишегалдын ялт иттермәкчеләр. Моның өчен 118 миллион сум акча тотылыр, дип фаразлана.

– Бездә район үзәге юк, ә шәһәрдән аермалы буларак, торак пунктларда күпфатирлы йорт тирәсендә хуҗаларга электән үк бүлеп бирелгән җирләр бар, – ди район башлыгы Фаил Камаев. – Берәүләр тәрәзә төбендә суган-кишер үстерсә, икенчеләре исә йорт янында гына мунча корып куйган. Ишегалларында гаражлар да бик күп. Шуңа күрә халык баштарак әлеге программага бик шикләнеп карады. Сөйләшә торгач, аңлаштык. Хәзер бергәләп эш итәбез. Без гаражларны күчереп бирергә дә риза. Дөрес, мунчаларга бик тимәскә тырышабыз. Бакчачыларның коймаларын рәткә китерергә булышабыз. Ишегалдында һәркем үзен хуҗаларча хис итәргә тиеш. Районда үзара салым акчасы да бар бит әле. Халык ризалыгы белән, аны да тирә-юньне төзекләндерүгә тотабыз.

Булганда – бүре, булмаганда – шүре дигәндәй, тузган ишегалдын рәткә китерә башлагач, күпфатирлы йортларда яшәүчеләр арасында кызу бәхәс чыккан очраклар да еш була икән. Йә машина кую урыннарын киметүләре ошамый, йә, киресенчә, җәяү йөрергә урын җитми. Әнә Казан ишегалларының берсендә өч елдан бирле эшкә тотына алмыйбыз, диделәр брифингта.

– Ишегалды территориясенә һәркем тигез хокуклы, – ди «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фонды директоры Наилә Зиннәтуллина. – Әмма кайда нәрсә булырга тиеш икәнен утырып сөйләшә башлагач, төрле фикерләр ишетергә туры килә. Мәсәлән, Чирмешән ишегалларының берсендә әбиләр күпфатирлы йорт янына балалар мәйданчыгы куюга гомумән каршы чыкты. Монда картлар гына яши, дип аңлаттылар. Тәрәзә төбендәге өстәл һәм эскәмияләр тирәсендә төнлә яшьләр җыелып ята, дип зар белдерүчеләр дә җитәрлек. Тик ишегалларын төзекләндергәндә, уртак фикергә килә белергә кирәк. Биредә һәркемнең мәнфәгатьләре исәпкә алынырга тиеш.

Бу мәсьәләдә бердәмлек бар анысы. Моны елдан-ел халыктан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләр саны кимүдән дә чамаларга мөмкин. Мәсәлән, ишегалларын төзекләндерүчеләр җиң сызганып эшли башлаган 2020 елда «Безнең ишегалды» программасының 8 (800) 27-5-2020 номерлы бушлай «кайнар линия»сенә 18 меңгә якын кеше шалтыратса, былтыр андыйлар саны 10 меңнән дә артмаган.

«Безнең ишегалды» программасын төгәлләгән районнар

Район исеме	Төзекләндерелгән ишегаллары саны
Актаныш	12
Әлки	12
Әтнә	2
Чүпрәле	4
Кайбыч	3
Кама Тамагы	28
Мөслим	16
Яңа Чишмә	20
Спас	19
Теләче	11
Ютазы	54

Түләүләр гаризасыз бирелә

Барлык геройлар (Советлар Союзы, Россия Федерациясе, Социалистик Хезмәт, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, Дан орденының, шулай ук Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары) һәм аларның гаилә әгъзалары айлык түләүләр алу өчен гариза һәм документлар тапшырудан азат ителә. Дәүләт Думасында шундый закон проекты беренче укылышта кабул ителгән.

Документта Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондына каһарманнарга түләүләр билгеләү турында хәбәр бирү йөкләнгән. Фонд Герой исемен бирү турында мәгълүматларны федераль башкарма хакимият органыннан, башка органнар һәм оешмалардан алачак. «Илебезне көчле, имин итү өчен гомерләре бәрабәренә барын да эшләүче геройлар, шулай ук аларның гаиләләре үзләренә тиешле түләүләрне бернинди гаризасыз һәм документсыз алырга тиеш», – дигән Дума Рәисе Вячеслав Володин.

Сүз уңаеннан, Советлар Союзы, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары февральгә кадәр – 74 мең 617 сум, ә инде Социалистик Хезмәт, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – 55әр мең сум күләмендә айлык түләү алып килгән. 1 февральдән түләү 11,9 процентка арткан.

Судан калмый

Татарстанда язгы ташу чорында су басудан саклану буенча чаралар планы расланган. Документ гадәттән тыш хәлләрне булдырмау, кешеләрне, йортлар, юл-күперләрне су басудан саклау максатында эшләнгән. Карарга Премьер-министр Алексей Песошин кул куйган.

Җирле үзидарә органнарына, гадәттән тыш хәлләрне, янгыннарны булдырмый калу комиссияләренә план нигезендә эшләүне контрольдә тоту йөкләнгән. 1 апрельгә кадәр алар Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына планны гамәлгә ашыру һәм язгы ташуны уздыру нәтиҗәләре турында хисап тотачак.

Планда, аерым алганда, районнарны язгы ташуга әзерләү, МЧС хезмәткәрләрен су басу куркынычы янаган авылларга алып килүне оештыру, кешеләрне, мал-туарны хәтәр урыннардан өлешчә эвакуацияләү планнарын аныклау күздә тотылган. Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы хезмәткәрләренә – калдыклар туплану урыннарында елга-күлләрнең су сыйфатын, агулы химикатларны һәм чистарту корылмаларын саклауны тикшерү, ә Эчке эшләр министрлыгына – сулыкларда боз «бөке»ләреннән котылу өчен шартлаткыч матдәләр алып баруны озату йөкләнгән.

Закон үтәгәнне ярата

Узган елда Татарстан инспекторлары җир законнарын бозуның 560 очрагын ачыклаган. 575 тикшерү нәтиҗәсе буенча 528 күрсәтмә бирелгән, шулай ук 5 миллион сумнан артыграк күләмдә штраф салынган.

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, 2022 елда Казанда якынча 170 закон бозу очрагы билгеләнгән. Районнар арасында бу күрсәткеч ягыннан Түбән Кама (28), Лениногорск (27), Актаныш (26), Биектау (25), Нурлат (23), Тукай (22), шулай ук Зәй (21) һәм Питрәч (21) алдынгылыкта бара.

Закон бозуларның күпчелеге җирдән документларсыз файдалануга (җирне үзбелдеклеләнеп алу) кагыла: 84 проценты шуңа туры килә. Икенче урында – җирдән тиешсез максатта файдалану (12%). 2шәр проценты күрсәтмәләрне үтәмәү һәм штрафларны түләмәүгә бәйле.

Авыручылар арта

Соңгы тәүлектә Татарстанда 79 кешенең ковид йоктыруы ачыкланган. Инфекциягә каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, 7 февральгә республикада коронавирус ияртүнең барлыгы 195777 очрагы теркәлгән. Бер тәүлек эчендә 58 сырхау (алдагы көнне – 15) хастаханәгә озатылган. Пандемия башланганнан бирле 192394 кеше савыккан, шул исәптән соңгы тәүлектә – 58 кеше. Татарстанда чирдән яңа үлем-китем очраклары теркәлмәгән. Бездә коронавирус инфекциясеннән җәмгысы 2010 кеше вафат булган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ярдәм янәшә!

Уртак кайгы

ТӨРКИЯ БЕЛӘН СҮРИЯ ФАҖИГАСЕННӘН РОССИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН ДА ЧИТТӘ КАЛМАДЫ

Бу көннәрдә барыбызның да йөрәкләре Төркия һәм Сүрия өчен сыкрый. Искәртеп үтик: дүшәмбе иртәсендә Төркиянең көньяк төбәгендә һәм аңа якын районнарда, Сүриядә җир тетрәде. Җимерек шәһәрләр, меңәрләгән үлүчеләр, тагын да күбрәк зыян күрүчеләр... Кызганыч, табигать афәтеннән гомерләре өзелгәннәр саны да, җимерекләр дә арта гына бара.

Бәла килгән дәүләтләргә үз ярдәмен 45 ил тәкъдим итте. Җитәкчелектән кайгы уртаклашу сүзләре, ярдәмгә мохтаҗ җирләргә коткаручы төркемнәр, белгечләр җибәрү, техника һәм башкасы белән ярдәм итү... Билгеле, мондый фаҗига вакытында Россия дә читтә калмады.

Россия оборона министры Сергей Шойгу боерыгы буенча, Сүриядәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә ил хәрбиләре дә катнаша. 10 җыелма төркем формалаштырылган. Алар хәрабәләрне сүтү, зыян күрүчеләрне эзләү, аеруча җимерек хәлдәге районнарда медицина ярдәме күрсәтү белән шөгыльләнә. Россия хәрбиләре Алеппо, Хама, Латакия һәм башка шәһәрләрдә эшли.

Моннан тыш 100дән артык коткаручы Төркиядә ярдәм күрсәтә. Алар югалган кешеләрне эзләү белән мәшгуль. Моның өчен махсус кирәк-яракны да алып килгәннәр.

Бу җәһәттән Россия Икътисадый үсеш министрлыгы ил халкына Төркиягә барудан тыелырга киңәш итте. Ял итү турында уйлый торган чак түгел, билгеле.

– Төркиянең үзәк һәм көньяк өлешләрендә сейсмик активлык арту сәбәпле, Кахраманмараш, Малатья, Диярбакыр, Малатья провинциясе, Газиантәп төбәгенә сәфәргә чыкмаска киңәш ителә, – диелә ведомствоның «Телеграм»дагы сәхифәсендә. Искәртүләренчә, ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен, «Турпомощь» ассоциациясе «кайнар элемтә» номерын булдырды: +7 (499) 678 12 03.

globallookpress.com

Чит-ят кайгы булмый, диләр. Төркиягә ярдәм күрсәтүдә Татарстан да читтә калмады, билгеле. Төркиянең Казандагы Генераль консуллыгы җир тетрәүдән зыян күрүчеләр өчен гуманитар ярдәм күрсәтү пункты ачты.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Андрей КАРТАПОЛОВ, Дәүләт Думасының Оборона буенча комитеты рәисе:

Язгы чакырылышта ук хәрби комиссариатлар 30 яшькә кадәрге гражданнарга повестка җибәрергә мөмкин. Шул ук вакытта законга, аерым алганда, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы законга төзәтмәләр кертү соралачак. Ә инде язгы чакырылышка кадәр һәр хәрби комиссариат яңа таләпләргә күпме кеше туры килгәнне ачыкларга тиеш.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – КАРШЕРИНГ

«ГТК-Холдинг» компаниясе хәбәр итүенчә, 2022 елда Россиядә яшәүчеләр каршерингка 26 млрд сум күләмдә акча сарыф иткән.

70%	>> 3–5 мең
20%	>> 3 меңнән азрак
10%	>> 5 меңнән күбрәк



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТӨРЕК ШОГЫ

Газета хәбәрчесе үткән тәүлектә Төркиядәге танышларыннан купсаннлы хәбәрләр алды. Җир тетрәү зонасыннан ерак шәһәрләрдә дә халык шок хәлендә, матди ярдәм җыела, диләр алар. Казаның масштабы, чынлап та, шок хәленә китерерлек. Адана мэры, 3 миллион кеше урамда, аларга азык-төлек белән ярдәм кирәк, дип чаң суга. Газиантәп мэры Фатма Шахин шулай ук: «1 миллион кеше өйләренә керә алмый. Бар җирдә дә алар өчен спорт үзәкләре, социаль оешмалар һәм мәчетләр ишекләрен ачты. Ипи пешерү белән проблемалар бар, чөнки табигый газ юк. Безгә ашыгыч рәвештә икмәк һәм одеяллар кирәк», – дип сөрән салды. Башка шәһәрләрдә дә вазгыять катлаулы. Бер Төркиядә генә түгел, Сүриядә дә хәл аяныч.

Дөньяның төрле почмакларыннан илгә коткаручылар отрядлары ашыга. Әмма күпме генә килмәсеннәр, фаҗигането масштабы фонында ярдәм аз. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы үлүчеләр саны 20 меңгә җитәргә мөмкин дип белдерде. Җимерекләр астыннан исән калган кешеләрне коткару дәвам итә. Алепподан (Сүрия) шаккатмалы хәл турында хәбәр килде. Авылы хатын җимерекләр астында исән-сау бала тапкан. Кызганыч, ана һәм гаиләнең башка әгъзалары үлгәннәр, ә яңа туган сабыйны коткаручылар исән килеш казып алды. Җимерекләр астында калучыларның телефон аша үзләренә ярдәм сорап хәбәр салу очраклары билгеле. Кочаклашып үлгән әти белән бала мәетен дә казып чыгардылар.

Төрек хакимиятләре, хәлдән килгәнчә, каза күрүчеләрнең хәлен җиңеләйтергә тырыша. Turkish Airlines компаниясе Адана, Диярбакыр, Шанлыурфы һәм Әлязыг һава аланнарыннан очучы очкычларга билет бәясен 100 төрек лирасына (378 сум) гына калдырды. Иң каты тетрәүгә дучар булган ун шәһәрнең ипи пешерүчеләре икмәкне бушлай өләшү турында карар кабул иттеләр. Төрек оппозициясе сайлау алдыннан (майда Президент сайлау көтелә) вазгыятьне сәяси очколар җыеп калу өчен файдалана. Оппозициянен партия вәкилләренең, җимерек шәһәрләргә килеп, хөкүмәт ярдәмгә җитәрлек күләмдә армия җибәрмәде, дип гаугa куптару очраклары бар.

Вәсвәсә таратучылар да активлашты. AFAD (Afet ve Acil Durum Yönetimi Başkanlığı) – стихияле бәла-казаларга каршы көрәшүче төрек агентлыгы Истанбул гражданнарын узган төнне (дүшәмбедән сишәмбегә каршы кич) урамда үткәрергә чакырып таратылган хәбәрләрне дезинформация дип бәяләде. Дүшәмбедә афтершоклар (кабат тетрәүләр) еш булды. Шул уңайдан Истанбулда куәтле тетрәү булачак дигән коткы таратылган. Сейсмологлар, чынлап та, Истанбулда 2030 елга кадәр зур җир тетрәү булачак, йөз меңгә кадәр кеше корбан булырга ихтимал дип кисәтәләр, әзерләнергә чакыралар. Сейсмолог Наҗи Гёрур: «Мин, галим буларак, фетнә кубарам. Истанбулда җир тетрәвенә бер генә оешма да әзер түгел», – дип шаулый.

Дүшәмбе көн Җир шарында сейсмик активлык бик көчле булды. Күп илләрдә тектоник плитәләр селкенде. Казахстаннан 5,4 балл магнитуда белән җир тетрәү турында хәбәр килде. Бәхеткә, җимерекләр юк.

Россиядә

МИЛЛИ БАЙЛЫК ФОНДЫ ҖИТӘРМЕ?

Россиянең – үз проблемасы: анда финанслар романс җырлый. Махсус хәрби операция башланганнан соң беренче тапкыр санкцияләрнең матди зыяны көн тәртибенә кискен булып килеп басты. Гыйнвар аенда бюджет дефициты 1998 елдан соң беренче тапкыр иң масштаблысы булды. Финанс министрлыгы рәсми рәвештә айлык дефицитның 1,76 триллион сумга җиткән әйтте. Дефицит – керемнәрнең 35 процентка кимүе нәтиҗәсе. Чыгымнарның 59 процентка артуы да үз сүзен кискен итеп әйтә. Дефицит фонында доллар күтәрелә, рубль төшә. Курс бер долларга 71 сумга җитте һәм бу, мөгаен, старт кына булыр. Финанс министрлыгы Милли байлык фондын ачып сата башлады инде. Гыйнварда 3,6 тонна алтын сатылган. Моңарчы хөкүмәт алтынны сатып кына ала иде. Барлык илләр дә шулай эшли агымдагы вазгыятьтә. Үткән ел Үзәк банклар рекордлы күләмдә алтын сатып алдылар, чөнки кәгазь валюталар ышанычсыз.

Бу уңайдан, «Милли байлык фонды җитәрме?» дигән сорау туа. Бюджет дефицитын елга 3 триллион сум тирәсе булыр дип рәсми фаразланганнар иде. Гыйнвар ае ук ул фаразларны чәлпәрәмә китерде инде. Фондта 10 триллион сум тирәсе акча бар. Шартлы сан бу, чөнки алтын һәм валюта курслары үзгәрсә, капчыктагы резервларның сумнардагы күләме дә үзгәрәчәк. Тагын бер нәрсә бар: триллионнарның барысын да тотып булмый, чөнки бер өлеше инвестицияләргә юнәлтелгән. Әйтик, юлга асфальт буларак салынган акчаны алып булмый бит инде. Милли байлык фондының ликвидлы өлеше (ягъни акчага әйләндереп була торганы) 6 триллион сум гына. Шулай ук шартлы сан. Алтынны күп сата башласаң, бәясе төшәчәк һәм фондтагы сумнар күләме кимечәк. Валюта белән дә шулай ук. Валюта курсын югары күтәреп, саклаудагы акчаның сумлата күләмен үстереп була. Фаразлый алабыз: акча станогын бар куәтенә эшкә җигәрләр. Бу Милли байлык фондына долларларда кимегәндә дә сумнарда үсәргә юл ачачак. 2014 елда хөкүмәт резервларны шулай саклап калган иде. Валюта паникасы оештырып, кризисны халык җилкәсенә салдылар.

Вазгыять гыйнвардагыча дәвам итсә, резервлар тиз төкәнәчәк барыбер. Аларны саклауның тагын бер юлы бар: облигацияләр сатып, әҗәткә җыю. Әҗәт кәгазьләрен күп сатарга туры киләчәк. Үзәк банк комерция банкларына репо аша акча өләшеп оештыра гадәттә облигация сатуны. Аңлыйсыздыр: акча басу бу. Бюджет дефицитын инфляция аша каплау. Инфляция авырлыгын кем күтәрә? Без һәм сез. Халык.

Көнбатыш Россия икътисадын җимерүче астыртын адымнарын дәвам иттерә. 24 февральгә санкцияләрнең унынчы пакеты әзерләнә. Безгә 10 миллиард еврога төшәчәк, диләр. АКШ Россия алюминиена 200 процентлы пошлина кертергә ниятли. Алюминий сатуның кимүенә китерәчәк адым ясала.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

МӨМКИНЛЕК ТӘ, ШАРТ ТА БАР

Эшчәнлекне яңа шартларда дәвам итәргә кирәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Казанкомпрессормаш» ачык акционерлык җәмгыятенә сәфәре барышында шулай дип белдерде. Анда Татарстанга эш сәфәре белән килгән «Газпром» акционерлык җәмгыятенең идарә рәисе урынбасары Виталий Маркелов та катнашты.

«Казанкомпрессормаш»ның цехлары белән танышу барышында алар механик җыю эшләре, җыю цехы эшчәнлеген өйрәнде. Моннан тыш аларга оешманың алга таба үсеш презентациясе тәкъдим ителде. Якын киләчәктә бердә яңа җыю һәм компресс җиһазларын сынау цехлары төзергә планлаштыралар.

Заводка сәфәр барышында оештырылган утырышта оешманың кайбер юнәлеш буенча эшчәнлегенә йомгак ясалды, үсеш программасының «юл картасы» уңаеннан фикер алыштылар. Татарстан белән «Газпром» акционерлык җәмгыяте хезмәттәшлеге кысасында уртак проектларны тормышка ашыру турында да сөйләштеләр.

Рөстәм Миңнеханов «Газпром»ны Татарстанның стратегик хезмәттәше дип атады. Татарстан Рәисе «Казанкомпрессормаш» ачык акционерлык җәмгыятенең үсеш программаларын тормышка ашыру өчен барлык мөмкинлекләрнең барлыгын да искәртте. «Бүген эшчәнлекне яңа шартларда дәвам итеп, моңа кадәр билгеләнгән планнарны тормышка ашырырга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Уртак кайгы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ул атна дәвамында, шул исәптән ял көннәрендә дә эшләячәк. Консуллыкта билгеләп үтүләренчә, балалар һәм өлкәннәр өчен җылы киемнәр, юрган, җылыткыч, палатка, йокы капчыклары, термос кебек кирәк-ярак алып килү сорала. Башкаладагы консуллык Горький урамы, 23/27 йорт адресы буенча урнашкан.

Моннан тыш Казандагы «Зәкәт» хәйрия фонды да Төркия һәм Сүриядәге афәттән зыян күрүчеләргә акчалата ярдәм күрсәтү турында игълан итте. Битараф булмаганнар фонд исеменә акча күчерә ала. «Берләшеп, ярдәм күрсәтик. Аларга безнең ярдәм бик кирәк. Зыян күрүчеләр азык-төлек, җылы кием, даруларга мохтаҗ», – диелә фондның игъланында. Акча җыю фонд сайтында бара.

Төркиянең Казандагы консуллыгында әйтүләренчә, аларда мондый бәла-каза вакытында чәчәкләр салу гадәте юк. Кайгы уртаклашу сүзләрен калдырырга мөмкин. Ихлас догада булыйк! Бәла-каза агач башыннан түгел, кеше башыннан йөри шул.

Төркиядә яшәүче милләттәшләребезнең хәлен белештек

Ләвант БУЛУТ,
мәрхүм хезмәттәшебез Алсу Хәсәнованың ире:

– Мин дә, туганнарым да исән-сау. Әмма куркып торабыз. Әле дә җир тетрәү кабатлануы ихтимал. Соңгы өч ел шулайрак яшибез инде без. Бездә бик салкын. 10 шәһәрдә җир тетрәде. Биш меңнән артык бина җимерелде. Күпме гомерләр өзелде! Бик авыр хәлләр. Безгә җир тетрәгән вакытта нишләргә кирәклеген аңлаттылар. Җир тетрәгәндә, йорттан ашыгыч рәвештә чыгып китәргә кушалар. Хәлемне белгәнегезгә рәхмәт!

Чулпан ГАРИПОВА,
бәйрәмнәр алып баручы, Төркиядә кышлый:

– Иртәнге бишенче яртыда уянып киттем. Кухняда ниндидер тавыш килә иде. Чыгып карасам, бар да тыныч. Телефонга үрелдем. Анда исә җир тетрәү турында яза башладылар. Башка шәһәрләрдә торучылар үзләренең урамга чыгулары турында яза иде. Бәлки безгә дә чыгаргадыр дип, балконнан карадым. Урамда берәү дә юк. Бары тик бер песинең генә ачыргаланып кычкырып йөргәнен күрдем. Шөкер, без яшәгән якта тыныч була. Мондагы халык бер-берсенә бик ярдәм итә. Анталиядә яшәүчеләргә дә таталар, җыелышып, ярдәм күрсәтә. Төркиядә халыкны кисәтү белдерүләре чыкты. Әлегә куркыныч. Һәркемгә чемодан әзерләп куярга кушылды. Чемоданга иң кирәк әйберләр, су, дарулар, җылы киемнәр, документларны, фонарь, батарейкалар, сызгычлар, шырпылар тутырып куярга киңәш ителә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БУЛГАННЫ САКЛАРГА!

Нәтиҗә

Әйләнә-тирәне саклау һәм табигать байлыкларыннан дөрес файдалану. Татарстанның төп бурычы – әнә шулар. Аларны хәл итү республиканың гына түгел, илнең үсешенә йогынты ясый. Бу хакта Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте Идел-Кама төбәкара идарәсенең еллык киңәйтелгән утырышында сөйләштеләр.

Идарә җитәкчесе Фаяз Шакиров сүзләренә караганда, узган ел инспекторлар 462 хокук бозу очрагы ачыклаган. Нәтиҗәдә 7 җинаять эше кузгатылган. Тирәлеккә сакчыл карамаган оешмаларга штрафлар салынган. Фаяз Шакиров үз чистарту корылмаларының зыянга эшләвен дә әйтеп узды. Шул рәвешле, узган елны табигатькә 333 миллион сумлык зыян салынган. Эре оешмалар да моңа үз өлешен кертә. Әйтик, Мари Иленда «Звениговo» оешмасы табигатькә 646 миллион сумлык зыян китергән.

Фаяз Шакиров Казанның «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләрнең һава пычраклыгыннан зарлануы турында сөйләде. Урынга чыгып тикшергәч, һавадагы формальдегидның күләме нормадан – 1,5, күкерт газының күләме 2,3 мәртәбә күп булуы ачыкланган. Сәбәпчесен дә тапканнар: бирегә һаваны пычратып ятучы полигон бар икән.

Полигон дигәннән, «Гринта» төбәк чүп җыю операторы директоры Светлана Ярлыченко да чүп куярга урын җитмәүгә борчыла. Кайбер полигонның эшләү вакыты чыкса да, куллану вакыты чыкмаган була. Менә шушы проблеманы хәл итәргә кирәклеген ешерми ул. Светлана Ярлыченко эшләгән эшләрен генә сөйләп калмады, чүпне урнаштыру мәсьәләсендәге җитешсезлекләр турында Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте (Росприроднадзор) җитәкчесе Светлана Радионовага да җиткерде.

Светлана Радионова республикадагы чүп мәсьәләсенә бар яклап ачыклык кертергә тырышты. Күпмесен икенчел чималга җибәрәләр, күпмесен утильләштерәләр, күмәргә дигәне ничаклы кала? Әнә шул сорауларга җавап эзләде ул.

– Чүпне атналар буе яткырып, аннан икенчел чимал алып булмый, – дип өстәде Мәскәү кунагы, киләсе елга бурычлар да куйды. Болар – чиста Идел, табигатьтән файдалануны контрольдә тоту, калдыкларны утильләштерү һәм тирә-якка зыян салуны кимету.

– Мин күзәтчелек органнарыннан табигатькә килгән зыянны исәпләү белән беррәттән, тирә-якка никадәр зыян салынуга да игътибарлы булырга тәкъдим итәр идем. Калдыкларның классын түбән күрсәтеп, азрак түләргә омтылучылар зыянны күбрәк сала бит. Шуңа күрә сак булыгыз, – диде ул.

Светлана Радионова күзәтчелек органнарына ярты ел эчендә үзләрендә инвентаризация ясарга да кушты.

Утырышта катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та Светлана Радионова сүзләре белән килешүен әйтте:

– Без – техноген республика. Шуңа да табигатькә сакчыл карарга, аның байлыкларыннан дөрес файдаланырга кирәк. Татарстанда меңләгән оешма эшли. Республика нефть, нефть химиясе, нефть эшкәртү, машина төзү буенча дан тота. Әйтик, Татарстанда 35,7 млн тонна нефть җитештерелгән, сәнәгать продукциясе күләме 6,6 процентка үскән. Бу күрсәткеч буенча Татарстан илдә дүртенче урында тора. Безнең бурыч – сәнәгать оешмаларының уңышлы эшләвен тәэмин итү генә түгел, халыкка уңайлы яшәү шартлары тудыру да. Шушы максаттан республикада «Экология» илкүләм проекты эшләп килә. Узган ел бу максатларга 6,8 млрд сум акча бирелде, – диде ул.

Татарстан Рәисе узган ел инвентаризация вакытында Татарстанда табигатькә зыян салучы 21 объект ачыкланганны да әйтте. Ул Светлана Радионовадан кайбер тәкъдимнәрне «Экология» илкүләм проекты кысасында башкарылучы «Генеральная уборка» проектына кертүне сорады.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, экология юнәлешендә көн кадагында торган беренче мәсьәлә бар: халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү, шулай ук сәнәгать һәм каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, элек пычранган җирләрне рекультивацияләү.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ФӘН ЭЗЛӘНГӘННЕ ЯРАТА

8 февраль – Россия фәне көне

Арпаны арыштан ничек аерырга? Арча кызы Дилә Сәйфетдинова бу культураларны Татар авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренүләр институтына килгәч кенә аерырга өйрәнә. Бүген инде ул – тәҗрибәле фәнни хезмәткәр. Аның белән фән дөньясына ничек килеп керүе, яшь галимнәргә мөнәсәбәт турында сөйләштек.

Дилә – Арча районының Көче Төрнәле авылы кызы. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясен тәмамлый. Юк, анда мал табибына түгел, сөт һәм май ризыкларының сыйфатын тикшерү өлкәсе буенча укый. Кулына диплом алгач, Татар авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренүләр институтының аналитик лабораториясенә эшкә керә.

– Ни бодай, ни арыш, ни арпаны аера белми идем әле ул вакытта. Авыл кызы булсам да, әти-әни колхоз, җир эшеннән читтәрәк йөрттә. Лабораториягә эшкә урнашып, ашлыкның сыйфатын тикшерү башладым. Бу эшне яратып башкардым. Ашлыкның гомуми сыйфаты формалашуы миндә зур кызыксыну уятты. Шул вакыттан бирле мин профессор, биология фәннәре докторы Пономарева Мира Леонидовна кул астында фәнни хезмәт белән шөгыльләнә башладым.

Бүген ул – көзге арыш һәм тритикале селекциясе лабораториясенә яңа сортларны булдыру буенча белгеч. Шул ук вакытта аспирантурада белем ала. Анда арыш һәм бодай буенча фәнни хезмәт яза.

– Селекция эшен бөтен кеше дә башкара алмый. Шул ук вакытта без, басуга чыгып, җирнең сулышын тоеп эшлибез. Чәчә буламы, коеп яңгыр явамы, син, басуга барып, үз эшеңне эшләп кайтырга тиеш. Урак вакытында кичкә кадәр калырга да туры килә. Яңгырлар кәтелсә, ял көннәрендә дә чыгабыз. Эшем бик ошый. Галимәдә дә аңлыйлар, – ди яшь белгеч. – Мин алтышар сорт арыш һәм бодай белән эш итәм. Узебез чәчәбез. Уңышны җыеп алып, складларда арыш авырлыгын үлчибез. Аннан алып кайтып тикшерәбез. Эшебез шундыйрак.

– Табигать үзгәреп тора бит, аннан соң инфекцияләр дә елдан-ел төрле. Кышка карап, яз көне көзге арыш начар чыгарга мөмкин. Урак өстендә яңгыр яуса, арышның сыйфаты кими. Төрле үзгәрешләргә илтүче, табигать күренешләренә бәйле сәбәпләрен, йогышлы авыруларга каршы торучанлыгын билгелибез. Мәсәлән, 2021 елда корылык булды. Аның әлеге культураларга тәэсирен ачыклыйбыз, – ди белгеч.

Диләнең басуга чыккан саен нәрсәгә булса да сөенеп кайта торган гадәте бар. Яз көне кырга чыккач та башка төрле хисләр били аны. Бөтен җир кап-кара. Ә ул утырткан көзге арыш ямь-яшел. Шул уҗымнарга карап шатлана. Көз көне исә башакның тулуын күрү – сөенечнең икенчесе.

Арыш үстерүче галимә, икмәк турында сүз чыккач та, бик зурлап сөйләде.

– Арыштан хәзер ак ипигә күчеп барабыз. Моны гаилә хәле яхшыру, акча ягына бәйләп аңлаталар. Әмма арыш ипиенең тәме дә, исе дә башка. Без аны онытмаска, ул безнең табынның китмәскә тиеш. Анда витаминнар да, аксым да күбрәк, – ди Дилә Сәйфетдинова.

Фән белән кызыксынган яшьләргә мөмкинлекләр җитәме? Яшь галимә, шартлар бар, әмма хезмәт хакы аз булу сәбәпле, алар фәнгә бик тартылмый, дип җавап бирде.

– Фән ул – энә белән кое казу. Иртәгә үрләр яулыйм, дип кенә уңышка ирешеп булмый. Озак вакыт, сабырлык таләп итә. Белемне яңартып торырга кирәк. Мин институтка 2009 елда килгән идем. Шуннан бирле гел эзләнүдә, укуда. Зур ачышлар ясамасам да, фәнни хезмәтләр язу да бик көч сорый, – диде галимә.

Сәрия МИФТАХОВА

«ВТ» архивыннан

БАРЧАГЫЗ ДА ИСТӘ, ОСТАЗЛАР

Без үскән, балигъ булып олы тормыш юлына аяк баскан 1950–1985 елларда Татарстанда республика күләмендә татар телендә бары өч газета: «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» һәм дүрт журнал: «Казан утлары», «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») белән «Ялкын» гына нәшер ителә иде.

«Татарстан коммунисты» (хәзерге «Татарстан») белән «Агитатор блокноты» (андый журнал чыкмый инде хәзер) бар икән әле тагын. Тик алары ике телдә тәрҗемәдә басыла һәм күбрәк партия әгъзаларына ярдәмлек рәвешендәрәк чыга иде.

Аз-маз каләм тибрәтүче бездәй балалар һәм үсмерләр чиле-пешле шигырьләребезне, мәктәп, авыл яңалыклары турындагы бер-ике битлек язмаларыбызны гадәттә район газеталарына һәм «Яшь ленинчы» белән «Татарстан яшьләре»нә, «Ялкын»га юллый идек. Анда эшләүче зур-зур шәхесләрдән – журналистлардан, язучылардан кош теледәй җавап алсак (редакциягә килгән һәр хатка, мәктәп баласымы син, берәр түрә-фәләнме, җавап бирү мәҗбүри иде ул елларда), еш кына ул «бу язмаң шигырь үк булып бетмәгән әле, язгалап тор» кебегрәк җавап булса да, кош тоткандай сөенә идек. Сирәгрәк булса да, редакция хезмәткәрләрен мин дә шулай җәфалый идем.

Илдар Юзеев киңәше белән (8 нче сыйныфтан башлап мин урау юллар аша Казанга килеп урнашканчы хат алыштык без), мәктәп тәмамлаганда журналист булу хыялым өлгереп җиткән булса да, бу өлкәгә мин соңрак килдем. Укырга керергә балларым җитмәү сәбәпле, 17 яшемдә үк, ялга кайткан авылдашларга ияреп, Урал якларына тимер юл эшенә китеп бардым. Романтика, янәсе. БАМ төзелеше бик популяр иде бит ул елларда. «Социалистик Татарстан» газетасына корректор булып эшкә урнашканда, мин инде Пермь – Свердловск якларында тимер юлда эшләп, бер семестр Урал тимер юл транспорты институтында укып, аннары аны ташлап, Казанга кайтып, Горбунов исемендәге атаклы авиация заводында, Казан медицина хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтында эшләп, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлап, ике бала табып үстереп ятучы яшь ана идем.

Ул елларда «Социалистик Татарстан» редакциясенә эшкә кешеләрне җиз иләктән үткәреп кенә алалар иде. Минем анда эшли башлавым могҗизага тиң бәхет булды. Моның өчен курсташым, «Татарстан яшьләре»ндә эшләүче журналист Рифкать Бикчуровка һәм татар милли матбугатының легендасы Шәех абый Зәбировка гомер буе рәхмәтлемен! Рифкатька – тәкъдим иткәне, Шәех абыйга – ышанганы, бүлектән бүлеккә, секретариатка күчергәндә дә иң саллы сүзләрне әйткәне өчен.

Корректор булып берничә ел эшләдем. Чөнки ул елларда журналистикада, бигрәк тә «Социалистик Татарстан» кебек партия басмасында хатын-кызлар бары тик корректор һәм машинкада текст җыючы, башка төрле техник хезмәткәрләр булып кына эшли иде. Безнең редакциядә хатын-кыз корреспондент исә берәү генә – республика матбугатының иң оста журналистларыннан саналучы, бүгенге буын бик күп каләм ияләренең остазы (мин дә аны үземнең остазларымның берсе дип саныйм) Илсөяр Хәйруллина. Ул да хезмәт юлын биредә корректор булып башлаган.

Ә нинди оста журналистлар, каләм ияләренең каймагы саналучы шәхесләр эшли иде ул вакытта редакциядә! Аларның һәммәсенең исеме республика журналистикасы тарихына алтын хәрефләр белән язылырга тиешле! «ВТ»ның 105 еллыгы уңаеннан, инде безнең буын тарафыннан да онытыла башлаган кайбер шәхесләрнең исемнәрен искә аласым килә. Газетабыз тарихында аларның да җуелмас эзе бар лабаса.

...Мирхәт Хөснимәрдановны күп каләм ияләре үзләренең остазы саный иде. Ул газетада эшләү белән беррәттән КДУның тарих-филология факультетының журналистика бүлегендә (соңрак ул факультет итеп үзгәртелде) остазлык дәресләре курсы мөгаллиме буларак та күпләргә һөнәрләрендә формалашырга һәм камилләшергә ярдәм итте. Хәер, факультет деканы Флорит

Имамәхмәт улы Әгъзамов һәм профессорлар Илдар ага Низамов, Васил Заһит улы Гарифуллин редакциянең легендар редакторы Шәмси ага Хамматов, Рәис ага Сабировлардан башлап күп кенә оста журналистларны бу эшкә даими җәлеп иттеләр.

Ул вакытта, партия органы буларак, газетаның теле дә, язмаларның тематикасы да бераз рәсмирәк иде. (Хәер, нигә яшереп торырга, башка газета-журналларныкы да шулайрак иде инде). Ә Мирхәт аганың теле һәм язмаларының төзелеше һәрвакыт башкаларныкыннан аерылыбрак тора. Кайбер сәбәпләр аркасында, ул редакциядән бер-ике мәртәбә бераздга китеп тә торды. Ләкин күпмедер вакыт узуга, аны редакторлар яңадан чакыртып алалар иде. Чөнки бик тә талантлы һәм кешелекле, тәрбияле, мөлаем, чибәр кеше иде ул.

Мирхәт абыйны мин дә үземнең остазым саныйм. Корректор булып эшләгән чагында ук яза башлаган беренче язмаларымның күбесе аның кулы аша узды, һәм аның алтынга тиң киңәшләре, күрсәтмәләре минем журналист булып формалашуым, камилләшүемдә гомерлек сабак булды. Ул бер абзац яки җөмлә белән дә, яисә берәр куплет җыр кыстырып җибәреп, яки җаен туры китереп, берәр риваять яки мәзәк өстәп куеп, язманы җанландырып җибәрергә сәләтле иде.

Редактор урынбасарлары Равил ага Сәгъдиев, Рафак ага Тимергалин да журналистларның осталыгын арттыру, газетаны кызыклы итеп чыгару өстендә күп эшләделәр. Равил абый үтә тыйнак, итагатьле, сабыр, журналистның һәр мәкаләсенә игътибарлы булып, аңа аерым бер мәгънә, юнәлеш биреп, ярдәм итә торган кеше булса, Рафак ага, кызу кеше буларак, җитешмәгән якларын турыдан бәреп әйтергә дә күп сорамый иде. Ләкин ниндидер төзәтү-мазар ясаганда яки киңәш биргәндә беркайчан да кешенең мин-минлегенә кагылмый, аны рәнҗетмәскә тырышып кына әйтә. Хаталарга да бик сизгер иде ул. Кайчак машинкада яки линотипта җыйганда кайбер язмаларда яки рәсми материалларда КПСС Үзәк комитеты, обком кешеләренең исем-фамилияләрендә берәр хәреф алышынган, төшеп калган булса, ул аларны шундук күреп ала иде.

Миргалим абый Харисов, кайчандыр Камал театрының атаклы щепкинчылары белән бергә укыган артист кеше буларак, әдәбият-сәнгать өлкәсендә бик белемле, киң мәгълүматлы иде. Телгә оста редактор буларак та журналистларның, бигрәк тә яшьләрнең язмаларын баета белә. Тиз кызып китүчән кеше буларак, кайчак кызартырга да күп сорамый. Ләкин, үпкәләтсә, гафу үтенә белә. Шуңа беркем дә аңа ачу һәм кинә сакламый иде.

Ярдәмчеллеге, яшьләргә аеруча игътибарлы булуы сәбәпле, Сәмигулла ага Хәйретдиновны бик күпләр әле дә сагынып искә ала. Ул, гомумән, беркемгә дә «юк, булмый», дип әйтә алмый иде бугай.

Ул чор журналистларыннан Зәйдулла абый Шәфигуллин, Дифгат ага Сираев, Нургали ага Булатов, Касыйм ага Тәхаутдинов, Мөшәррәф Галиев һәркайсы талантлы булулары өстенә үзенчәлекле шәхесләр дә иде. Зәйдулла абый, мәсәлән, яшь каләм ияләренең язмаларын кат-кат эшләтә, шул рәвешле эшкә дә өйрәтә иде. Редакциянең профсоюз рәисе буларак та бик күпләргә яхшылыгы тиде. Шулай ук Сәмигулла ага Хәйретдиновның, Мәгъсүм ага Гәрәевнең дә. Гомумән, редакциябезнең ул чор журналистлары бик тә абруйлы, теләсә кайсы дәрәҗәдәге җитәкче белән турыдан-туры аралаша, чишелмәстәй тоелган проблемаларны да хәл итә алалар иде.

Дифгат ага тәнкыйть мәкаләләрен оста язучы буларак истә калган. Нургали абый – үтә кешелекле, сабыр булып, һәркемгә, бигрәк тә яшьләргә ярдәм итәргә әзер булуы белән. Мөшәррәф исә бик тә җор телле. Аның бәйрәмнәргә төртмә телле шигырьләре белән чыккан әллә ничә метрлы стена газеталарын укып көлә-көлә эчләр катып бетә иде. Кызганыч, ул бик иртә китте.

Партия газетасы буларак, без республикада гына түгел, Мәскәүдә булган вакыйгаларга да бик нык бәйле идек. Кайбер хәбәрләр, хәтта докладлар аннан Телетайп ябылганда – кичке 8ләрдә генә килеп ирешә. Телетайп шимбә көнне дә эшли. Шул исәптән редакциянең дежур төркеме дә якшәмбегә яңа сан әзерли. Әле бит аннан килгән матераилларны тәрҗемә итеп, машинкада бастырырга, аннан типографиядә линотиписткалардан һәр хәрефне кулдан җыйдыртып, версткаларга да кирәк. (Ул елларда компьютер, интернетларның эзе дә, исе дә юк әле, барысы да кул хезмәте белән башкарыла.) Тәрҗемәчеләребез Әмин ага Раков белән Мәгъсүмә апа Гарипова шулкадәр осталар: машинисткаларга турыдан-туры әйтеп торып кына тәрҗемә итәләр. Гәрчә аларга тәрҗемә итеп мәшәкатьләнергә туры килмәсә дә, без иртәгә иртән газета укучыларның өстәлендә булачак яңа санны типографиягә басарга «Советская Татария» (хәзерге «Республика Татарстан») газетасы белән бервакытта диярлек тапшыра идек.

Коллективыбыз зур, әмма бик тә тату, бердәм иде безнең. Өлкәннәр яшьләрне яратып, яшьләр аларны хөрмәт итеп, алардан остазлык буенча да, кешелеклелек буенча да үрнәк алып яшәдек. Шул ук традицияне бездән соң килгәннәргә тапшырырга тырыштык. Әнә шуңа күрә дә «Ватаным Татарстан» газетасы бүген дә журналистлар арасында иң абруйлылардан санала. Бирегә аларны эшкә әле дә җиз иләктән үткәреп кенә алалар.

Люция ФАРШАТОВА

Дөньяга караш үзгәрде

Ватан хакына

Улымны балалар уратып алгач, дөньядагы бәхетле кешегә әйләндем. Солдат анасы, Питрәч районының Пимәр авылында яшәүче Рәмзия Галәвиева әнә шулай хис-кичерешләре белән уртаклашты. Улниләр кичерүе, нәрсәгә өзгәләнүе, тормышының ничек үзгәрүе турында сөйләде, теләкләрен җиткерде.

Бу гаилә белән элемтәгә чыгуыбыз юкка түгел. Социаль челтәрләрдә култык таягына таянган егетнең туган якка кайтуы, иң элек әнисе эшләгән мәктәпкә чәчәкләр күтәреп керүе күңелдә матур хисләр калдырды. Кем бу егет? Әнисе кем? Шушы сорауларга җавап эзләү Пимәр авылында гомер итүче Галәвиевләрне таптырды да инде.

Укытучылар гаиләсе бу. Рашат абый гомере буе балаларга музыка дәресен укыткан. Төрле авыллардан килгән укучыларны Ленино-Кокушкино сәнгать мәктәбендә аларны милли уен кораллырында уйнарга өйрәтә икән. Рәмзия апа исә 28 елдан артык башлангыч сыйныф балаларын укыта.

– Улыбызга повестка килгән көнне әле дә хәтерлим. Җибәрәсебез килмәсә дә, улым, чакыргач, барам, диде. Беренче эшелон белән китте ул. 23 октябрьдә махсус операция зонасында иде инде. Ул чакта ниләр кичергәнне сөйләп бетерерлек түгел. Күзге көнгә ияреп, күңел дә елады, – ди Рашат абый. – Без улым Ришат белән атнага бер булса да сөйләшеп тора алдык. Госпитальгә эләгүен дә иң элек миңа шалтыратып әйтте. Аның аякларына зыян килгән. Бер айдан артык дәвалангач, өйгә кайтарып җибәргәннәр. Әнисе янына керәсен мин белә идем. Рәмзиягә сюрприз булсын дип сиздермәдем.

Рашат абый белән Рәмзия апа өч бала үстерәләр. Олы уллары Рәлиф белән Ришатның яшь аралары бик якын, алар бер-бер артлы туган. Олысы армиядән кайткач, заводка эшкә кергән, өйләнгән. Өченчесе – кызлары 8 нче сыйныфта укый әле. 26 яшьлек Ришат әлегә өйләнмәгән.

«Землянкада ятканда да әти-әниемне уйладым», – ди Ришат Галәвиев.

– Мин алдан ук әйтеп куйдым: повестка килә икән – китәм. Илне кем сакләр соң, дидем. Күңелдә курку да юк иде. Әмма анда баргач, дөнья үзгәрде. Кайчан ни буласын белмичә яшибез икән. Кырыс шартлар яшәүнең кадерен аңлатты. Миңа анда акыл керде. Без тынычта, рәхәттә яшәгәнбез, дидем. Землянкада йоклаганда да, үземне түгел, әти-әниемне уйлый идем. Алар нишли икән, мине уйлап йокламый яталармы, дия идем. Якыннарым йөрәк түрендә булды, – ди Ришат. – Әмма андагы егетләр иң кадерле, якын дусларга әйләнделәр. Кешелеклелек! Менә кая барып табасы икән аны. Алайса, без монда рәхәткә чыдый алмыйбыз. Мин туган якны бик сагындым. Исән-сау кайта алсам иде, дип теләдем. Үлем янәшәндә йөргәндә, догалар да укыйсың, тәүбәгә дә киләсең. Яшәргә өйрәнәсең. Иң авыры – дусларны югалту. Ул авырлыкны әйтеп аңлатырлык түгел. Тик елыйсы килсә дә, елап булмый. Анда алай ярамый. Дошман сагалап кына тора.

Ришатның тормышка карашы, кешеләргә булган мөнәсәбәте үзгәргән. Әти-әнисенең кадере тагын да арткан.

– Самолетта очканда әниемне сөендерәм әле дигән уй килде. Чәчәкләр алып, ул эшли торган Татар Тау Иле мәктәбенә керәсе иттем. Әнием елак түгел ул. Мине күргәч, күзләре яшьләнде инде. Ә мин аны шундый сагындым! Бөтен пешергән ризыкларын, җылы кочагын, назлы кулларын сагындым. Кая гына барсаң да, ничә яшьтә булсаң да, әни кирәк, – ди Ришат.

Әнисе Рәмзия апа улын озаткандагы кичерешләрне менә хәзер генә сөйли әле. Ул чакта йөрәгемне кая куярга белмәдем, ди ул.

– Улым киткәч, тормыш үзгәрде. Элеккеге тыныч яшәүләр бетте. Эшемдә дә авыр булды. Әмма кечкенә сабыйларны укытуым коткарды. Интернеттагы хәбәрләрне укымаска тырыштым. Ике улымны бергә армиягә җибәрүләремне, аларны көтеп каршы алуларымны уйлап юандым. Кайттылар бит әле, монысыннан да кайтыр, дидем, – ди Рәмзия апа. – Мәктәпкә кайтып керүен күргәч, эчемдә горурлык хисе уянды. Баламның имгәнеп кайтуын да онылттым. Кайткан бит, дим! Шул арада улымны укытучылар, укучылар уратып алды. Мин дөньядагы иң бәхетле кешегә әйләндем. Бәхет килсә, өелеп килә бит ул. Иртән олы улымның кыз баласы туган иде. Әби-бабай булган көнне Ришатым да кайтып сөендерде. Мин бу бәхетле мизгелләрне ирләрен, улларын, әтиләрен көтүче һәркемгә телим. Шатлык яшьләре генә түгелсен, сөенеп яшәргә насыйп булсын иде.

Ришат әлегә ике ай буе табибларга күренеп торачак. Аякларына катлаулы операция ясаганнар. Пластина, шөрепләр куйганнар. Савыга башлагач, аларны алабыз, дигәннәр.

– Кабат китүдән курыкмыйм. Сәламәтлегем ничек була инде. Андагы хәлләрне күргәч, үземнең егетләр янында кирәклегемне беләм. Бер алманы бишкә бүлгән дуслар калды бит анда, – ди Ришат. – 3 ай эчендә мин зур сабак алдым. Андагы көннәр, төннәр елларга тиң булды. Бу хәлләр тәмамлансын, илгә тынычлык урнашсын иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе

КУЗЮРОВ Афраим Хәлиулла улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры Кузюров Равил Афраим улының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, әнисе

Сәүдә Хуҗи кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Теләче районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Низаметдинов Ралиф Хәниф улының авыр кайгысын уртаклаша.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Фахразиевым Илфатом Рашитовичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-261, с 03.05.2012 г. состоит в СРО Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья, реестровый номер 0028), адрес: 423445, РТ, Альметьевский район, с. Новое Каширово, ул. Гагарина, д. 7, кв. 2, тел.: 89179335383, email: ooo_stelscom@mail.ru, подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельной доли Хасаншиной Сании Хасановны, общей площадью 7 га, Мансуровой Гузял Ибрагимовны, общей площадью 7 га, Миназова Радика Нафисовича, общей площадью 7 га, Миназовой Таслимы Нигматзяновны, общей площадью 7 га, Миназова Нафиса Хасановича, общей площадью 7 га, из земельного участка с кадастровым номером 16:07:000000:660, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, Старомихайловское сельское поселение.

Заказчиком работ является Бадикова Альбина Фанисовна (Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, г. Альметьевск, ул. Фурманова, д. 13Б, тел.: 8-9172988670).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, г. Альметьевск, ул. Герцена, д. 88, пом. 1038/1, офис ООО «СтелсКом».

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.*

* п. 8, п. 11 ст. 13.1 Федерального закона от 24.07.2002 г. № 101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения».

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Фахразиевым Илфатом Рашитовичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-11-261, с 03.05.2012 г. состоит в СРО Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья, реестровый номер 0028), адрес: 423445, РТ, Альметьевский район, с. Новое Каширово, ул. Гагарина, д. 7, кв. 2, тел.: 89179335383, email: ooo_stelscom@mail.ru, подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельной доли Фаттахова Шакирзяна Галимзяновича, общей площадью 7 га, Насыбуллина Габтулбарея Хайевича, общей площадью 7 га, Кадыровой Гельфии Каримулловны, общей площадью 7 га, Миндияровой Ольги Гиздулловны, общей площадью 7 га, из земельного участка с кадастровым номером 16:07:000000:660, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, Старомихайловское сельское поселение.

Заказчиком работ является Бадикова Альбина Фанисовна (Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, г. Альметьевск, ул. Фурманова, д. 13Б, тел.: 8-9172988670).

С проектом межевания можно ознакомиться ежедневно с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, Альметьевский муниципальный район, г. Альметьевск, ул. Герцена, д. 88, пом. 1038/1, офис ООО «СтелсКом».

Обоснованные возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения.*

*п. 8, п. 11 ст. 13.1 Федерального закона от 24.07.2002 г. № 101-ФЗ «Об обороте земель сельскохозяйственного назначения».

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагы чыгарылышын ГӨСЛӘгә багышлыйбыз. Элек әлеге кыллы чиртмә уен коралы Татарстанның төньяк-көнчыгыш районнарында, аеруча керәшен татарларында киң таралган була.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

ГЕННАДИЙ МАКАРОВ: «ГӨСЛӘДӘ БОРЫНГЫ УЕН КОРАЛЛАРЫНЫҢ АҺӘҢЕ САКЛАНА»

Гөсләнең абруен ничек күтәрергә? Аның аһәңендә ниләр яшеренгән? Ни өчен электән гөсләдә күбесенчә хатын-кызлар уйнаган? Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать белеме кандидаты Геннадий МАКАРОВ белән әнә шулар турында әңгәмә корып, гөслә ясау серләрен өйрәндек.

:: Геннадий Михайлович, гөслә төзелеше һәм яңгырашының тарихи үзенчәлекләре турында сөйләгезче.

– Гөсләнең конструкциясен карасак, ул Европада таралган псалтериум уен коралына охшаган. Ә ул, үз чиратында, якын Көнчыгышка – Византиягә барып тоташа. Димәк, ул, борынгы заманда христианлык цивилизациясе тарала башлагач, Европага, аннан русларга һәм шуннан соң Кама буе халыкларына үтеп кергән дип фаразлыйм мин. Бу исә бер халыкның да изоляциядә яшәмәве турында сөйли. Ягъни гөсләне төрле халыклар арасындагы мәдәни аралашуның бер күрсәткече буларак та билгеләргә мөмкин.

Яңгырашына килгәндә, гөсләдә бүгенгә кадәр сакланып калмаган борынгы күпкыллы уен коралларының аһәңе саклана. Гөслә ятаган, чәң, канун кебек уен коралларының булганлыгын, алай гына да түгел, татар тарихының ни дәрәҗәдә катлаулы булуын исбатлый.

Кызганыч, бүген без чын гөслә тавышын ишетә алмыйбыз. Элек аның кылларын сарык эчәгеннән ясаганнар. Гомумән, аны ясаганда бары тик табигый элементлар гына кулланылган. Шуңа да элек-электән, гөслә тавышына фәрештәләр килә, дигән ышану яшәгән. Хәзер исә гөсләнең кыллары тимердән ясала.

Гөсләнең төзелешен күбрәк көйләр уйный алырлык итеп үзгәртергә кирәк, диючеләр бар. Юк, кагылырга ярамый аңа! Гөсләнең пентатоникага (биш баскычлы музыкаль рәт. – **Авт.**) корылган яңгырашын сакларга кирәк, аның бөтен үзенчәлеге шунда бит.

:: Элек-электән гөсләдә күбесенчә хатын-кызлар уйнаган. Моның сәбәбе нидә?

– Кызганыч, моның төгәл сәбәбен ачыклап булмады. Үзем болайрак фаразлыйм: эчке сыйфатлары, холкы буенча хатын-кыз – бик консерватив зат. Ул электән ыруның, өйнең учагын саклаган. Ә ирләр һаман алга, яңалыкка таба чапкан. Милли киемне дә беренче булып ирләр бетерде бит. Гомумән, теләсә кайсы традицияне шулай. Саклау, туплау – хатын-кызга хас сыйфатлар. Гөсләдә дә менә шул чагылгандыр дип уйлыйм мин. Электән кыз балага, тугач та, гөслә бүләк итсәләр, ир балага хәле булган кеше гармун алып биргән. Ә гармун ул – яңарак күренеш.

:: Гөслә ясау өчен күпме вакыт кирәк?

– Башка эшләргә бүленмичә ясасаң, атна-ун көндә ясарга буладыр.

:: Татарстанда сездән кала гөслә ясаучылар бармы?

– Юк. Һәрхәлдә, мин башка кешене белмим. Татарстаннан читкәрәк чыксак, Мари Иленең Йошкар-Ола шәһәрендә яшәүче Гәрәй Мәгъсүмҗанов атлы оста бар. Әмма гөслә ясаучылар тагын да барлыкка килер дип уйлыйм. Моңа ихтыяҗ бар.

:: Гөсләдә уйнаучылар, уйнарга теләүчеләр бар һәм җитәрлек ягъни?

– Мисаллар җитәрлек. Әйтик, Балтач районында Айсылу Әсәдуллинаның ансамбле бар. Һәм алар шактый уңышлы гына эшләп килә. Ләкин араларында яшь буын юк диярлек. Димәк, балаларны өйрәтү юлын табарга кирәк. Аннан соң, минем янга килеп, гөсләдә уйнарга өйрәтүемне, я булмаса гөслә сораучылар да бар. Моннан тыш, бу атнада Арчада икенче мәртәбә гөслә фестивале узачак. Фестиваль кадәр фестиваль уздырабыз, ә гөслә ясаучыларыбыз юк! Әйе, без ул фестиваль кысасында гөслә турында сөйләячәкбез. Ләкин бу хәл Хуҗа Насретдинның бер мәзәгенә охшап кала. Хуҗа Насретдин дусларына хәлвәнең баллы һәм тәмле булуы турында сөйли икән. Дуслары: «Каян беләсең?» – дип сорагач, «Әти сөйләде, ул базарда ишетеп кайткан», – дигән. Гөслә турында да күпме кирәк, шуның кадәр сөйләп була, әмма сөйләп кенә тамак туймый шул…

:: Сезнеңчә, бу проблеманы ничек хәл итеп була? Гөсләнең һәм, гомумән, борынгы уен коралларының абруен ничек күтәрергә?

– Беренче чиратта, гөслә ясау буенча төрле курслар кирәк. Әйтик, Мәдәният институтында Гамәли сәнгать кафедрасы бар. Алар, һичшиксез, бу проблемага йөз белән борылырга тиеш. Шул ук вакытта фән кирәк. Әйтик, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында музыка уен коралларын өйрәнү буенча аерым юнәлеш булырга тиеш. Мөмкинлекләр бар, безнең эчке мәдәни сәясәтебез дә шуңа юнәлдерелгән. Халыкка да кирәк ул! Республика ул кадәр үк ярлы түгел, аны гына күтәрерлек югыйсә.

Фән, укыту һәм уен кораллары җитештерү – менә шушы юнәлешләрне көчәйтергә кирәк. Бу эшне башларга җәмәгатьчелек әзер, җитәкчелек тә әзер кебек. Европадан ким җиребез юк хәзер. Шул ук вакытта үз йөзебезне дә саклап калырга тырышабыз. Ләкин җитлегеп бетмәгән урыннарыбыз да шактый. Менә шуларга йөз тотарга вакыт җитте.

ГЕННАДИЙ МАКАРОВ ОСТАХАНӘСЕННӘН ВИДЕОРЕПОРТАЖ

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Сәгыйть ХӘБИБУЛЛИН, дирижёр, педагог, профессор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Гөслә – борынгыдан бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган сирәк уен коралларының берсе. Ул борынгы дастаннарда, риваятьләрдә үк телгә алына.

Кыллы уен коралларын гомумән алсак, алар укҗәядән барлыкка килгән дигән фараз бар. Җәягә тарттырылган кылны чиртсәң, ул үзенә күрә тавыш чыгара. Шул тавышны ишетеп алып, сугышчылар гына кулланган кыллардан төрле уен кораллары ясый башлаганнар булса кирәк.

> Кол Галинең XIII гасырга карый торган **«Кыйссаи Йосыф»** поэмасында атамасы «гүс» яки «күс» дип укыла торган уен коралы турында телгә алына. Әлеге уен коралы һәм гөслә ничек тә булса бәйле булырга мөмкин.*

Гөсләнең исә Идел буенда яшәүче халыкларда (татарлар, чуашлар, марилар, удмуртлар) элек-электән кулланышта булуы билгеле. Әлеге халыкларның гөсләләре рус гөсләләреннән башкару алымнары белән аерылып торган. Шул ук вакытта һәр халык уен коралын үз көйләренә яраклаштырып үзгәрткән.

> **«Казан елъязмасы»**нда Казан Кремле сакчыларының, Иван IV гаскәренең чигенүен күреп, гөсләләрдә уйнап шатланышуы, күңел ачуы әйтелә.*

Гөслә Татарстанның төньяк-көнчыгыш районнарында, аеруча Саба, Арча һәм Балтач районы авылларында киң кулланышта була. Ул авылларда гөсләсе булмаган гаиләләр сирәк очрый. Аеруча керәшен татарларында. Электән кыз бала гөсләдә уйный белергә тиеш була. Гөслəчеләр төрле бәйрәмнәрне, күңел ачу чараларын калдырмый диярлек. Элек гөсләдә җырларны да, бию көйләрен дә уйнаганнар.

> Татар гөсләләренең төзелеше шлем формасындагы гөсләләргә якын. Гөслә кылларының саны **10нан 21гә кадәр** җитәргә мөмкин. Нигездә, 12 кыллы гөсләләр ешрак очрый. Гөсләне тезләрдә яссы тотып, башын үзеңә каратып, кайчакта өстәлгә яткырып уйнарга мөмкин.*

Тарихтан тагын бер кызыклы факт. 1940 елның 26 апрелендә Мәскәүдә Татар декадасын үткәрү турында карар чыгарыла. Беренче «Татар сәнгате декадасы» 1941 елның августында узарга тиеш була. Бу тантанага әзерләнүгә зур көч куела. Әлеге чарада Балтач районыннан бик күп гөсләчеләр катнашырга тиеш булуы билгеле. Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, татар декадасы кичектерелә.

Гөсләгә бөтенләй югалу куркынычы янаган чаклар да була. Кайбер очракларда бу яңа төрле уен кораллары барлыкка килүгә бәйле. Яңалары халык арасында танылу алу белән, элеккеләре онытыла. Гөслә язмышындагы иң катлаулы вакытларның берсе – совет чоры. Ул чакта бик күп милли республикаларда борынгы уен кораллары юкка чыга, аларны саклап калырга тырышучыларны милләтчелектә гаеплиләр. Фольклор уен кораллары кулланылыштан гына түгел, хәтта фәннән, уку-укыту программаларыннан да төшеп кала. Уку йортларына алар әле күптән түгел генә кайтарыла башлады. Моннан 40 еллар тирәсе элек гөслә турында мәгълүмат бөтенләй диярлек булмаса, хәзер инде без аны зур сәхнәләрдә дә күрәбез, тавышын ишетәбез.

*Мәхмүт Нигъмәтҗановның «Татар халык музыкасы» китабыннан өзекләр

Моңлы ядкәр: проблема һәм чишелеш

«Милли аккорд»ның беренче чыгарылышында, тальян язмышы – энтузиастлар кулында, дигән идек. Балтачның «Орчык» гөсләчеләр ансамбле җитәкчесе Айсылу ӘСӘДУЛЛИНА белән, гөслә дә шул ук кулларда, дигән фикергә килдек.

Балтачның **Субаш, Биктәш, Дорга** авыллары һәм Арчаның **Сәрдәбаш** авыллары электән гөсләдә уйнаучылары белән дан тоткан. Балтач районында исә бу традицияләрне Айсылу Әсәдуллина җитәкли торган **«Орчык»** фольклор ансамбле дәвам итә.

– Балтачта яшәп, районыбызда чын гөсләчеләр барлыгы турында белмәгәнмен. Алар турында Казан дәүләт консерваториясендә укыганда Геннадий Макаров сөйләде. Кызыксынуым мине Субаш авылында яшәүче Лиза апа янына алып килде. Аның белән танышып, гөсләдә уйнавына гашыйк булып кайттым. Һәм диплом эшемне шушы уен коралына багышладым. 2013–2014 елларда Балтач һәм Арча районнарына экспедицияләр оештырдык. Ул чакта шактый мәгълүмат җыелды. Борынгы көйләрне барлап, аларны нотага салып, бер җыентыкка тупладым. Ул көйләрне әле дә уйныйбыз, – ди ансамбль җитәкчесе.

«Орчык» ансамбле 2014 елда оеша. Күз карасы кебек саклап тора торган, Гәрәй Мәгъсүмҗанов ясап биргән биш гөсләләре бар. Өлкәннәр көйләрне нотага карап уйнаса, балаларны, нәкъ әүвәлгечә, кулдан тотып, я булмаса телдән әйтеп өйрәтә икән Айсылу ханым.

– Гөслә тавышы берәүне дә битараф калдырмый. Шул исәптән балаларны да. Шөкер, яшь буын арасында да кызыксынучылар бар, – дип сөендерде әңгәмәдәшебез.

Ләкин бу кызыксынуны тагын да арттырырга мөмкин. Әлегә **хәбәрдарлык җитми**. Бу – беренче мәсьәлә.

– Яшь буынны гына түгел, өлкәннәрне дә кызыксындырырлык чаралар җитми. Бездә гөсләдә уйнарга өйрәтүләрен белгәч, балалар бармаклары авыртып беткәнче уйнады. Ә бит бу уен коралы турында бөтенләй дә ишеткәне булмаган кешеләр бик күп, – диде Айсылу Әсәдуллина.

Бу мәсьәләгә карата уңай мисаллар да бар. «Орчык» кебек ансамбльләргә үзләрен күрсәтергә фестиваль-конкурслар ярдәм итә. Татарстанда икенче ел рәттән гөсләгә генә багышланган «Гөслә fest» уза. Бу очракта мондый чараларның санын түгел, сыйфатын арттыру әһәмиятлерәктер.

Ә иң авырткан җир – **гөслә ясаучылар булмау**. «Орчык» ансамбле мисалында гына карыйк. Хәзерге вакытта ансамбльгә сигез кеше йөри. Сүз уңаеннан, аларның икесе – балалар. Өч кешегә гөслә җитми.

– Юкка гына әйтмим моны: ихтыяҗ чыннан да бар. Гөсләнең борынгыдан килгән үзенчәлекләрен исәпкә алып, заманча юнәлешкә бирелмичә генә ясаучы осталар булсын иде, – дип аңлатты әңгәмәдәшебез.

Айсылу ханым – гөслә язмышы өчен янып йөрүче энтузиастларның берсе. Андый кешеләр булу бик яхшы, билгеле. Әмма гасырлар аша безнең көннәргә килеп җиткән уен коралының **язмышы өчен энтузиастларның гына борчылуы** – зур проблемаларның чираттагысы.

– Үземнән чыгып әйтәм: миңа бу коллектив өчен бер тиен дә түләнми. Кайчандыр грант отканнан соң миңа теркәлеп калган ансамбль ул. Кемдер грант отып, бер ел эшли дә, шуның белән шул. Без, шөкер, туктарга җыенмыйбыз. Репетицияләребезне «терапия» дип атаучы, җыелган җирдән кайтып китәргә теләмәүче кешеләрем бар. Ә бит үзең уен коралын яратмасаң, хөрмәт итмәсәң, бу хисләрне башка кешегә җиткерә алмыйсың, – ди ул.

Бу – кызык!

- «Гөслә» атамасын йөрткән музыка уен кораллары күп кенә славян һәм фин-угор халыкларында очрый: серблар һәм болгарларда – гусле, хорватларда – gusle, guzla, gusli, словеннарда – gosle, полякларда – guslic, чехларда – housle.
- Гөслә – арфа, кифара, лира, псалтерий кебек уен кораллары белән тугандаш.
- Гөслә ясау өчен биш-алты төрле агач кулланыла.
- Чын гөсләнең кылын чирткәч, ул унга кадәр санаганчы чыңлый.
- Гөсләнең берничә төрле формасы билгеле. Нигездә ул шлем формасында була. Моннан тыш, 2015 елда фольклор белгече Эльмира Каюмова тарафыннан өстәл рәвешле гөслә барлыгы ачыклана. Бу гөсләнең хуҗасы – Мари Иленең Мари-Төрек районы Верхний Мир авылында туган Галина Владимирова.
- Гөсләдә уйнаучыларга мәдхия җырлаганнар:
  Уңган кызлар гөслә чиртсә,
  Җырлар сибелә генә...
- Уйный белмәүчеләрдән исә көлгәннәр:
  Унике генә кыллары,
  Гөсләгә килми куллары.
  Картаеп торып калдылар
  Никулай дәдәй кызлары...

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде. Заказ 219

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт. График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+